**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**15 ноябрь 2024  ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге  131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2025 елда 600 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы территориясендә :«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары ,Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән,  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1. Чураш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, тракторчыга түләү)
2. Чураш Торак пункт территориясен төзекләндерү (кайнар нокта ветераннары өчен истәлекле стендлар сатып алу һәм урнаштыру;  Чураш  паркын койма белән әйләндереп алу, Беларусь МТЗ 82.1 тракторының ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 145 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -  75 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 75 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен  0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныйрга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныйрга.
2. «2025 елда 600 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш  авылы :«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1. Чураш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, тракторчыга түләү)
2. Чураш Торак пункт территориясен төзекләндерү (кайнар нокта ветераннары өчен истәлекле стендлар сатып алу һәм урнаштыру;  Чураш  паркын койма белән әйләндереп алу, Беларусь МТЗ 82.1 тракторының ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:  кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш  авылы мәгълүмати стендларына  урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева